**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче**
**Артамоновка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

28 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 28 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Артамоновка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 11 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 4 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Артамоновка авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә түгел дип танырга.

2. «2021 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Артамоновка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә

500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителмәгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл жирлеге Артамоновка авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

4. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Артамоновка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина